**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы № 115 «03» сентябрь 2018 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

"2019 елда Чалпы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан тыш, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

3) ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;

5) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

6) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Чалпы авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленин ур., 130 й. ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы бинасында, ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Чалпы авылы, Үзәк мәгълүмат стенды Чалпы табиб амбулаториясе бинасында; ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы Үзәк ур., 35 нче йорт; ТР Азнакай районы мәдәният йорты бинасында һәм кибет бинасында мәгълүмат стенды; ТР Азнакай районы Балан-Бүләк авылы мәдәният йорты бинасында һәм кибет

бинасында мәгълүмати стенд;  ТР Азнакай районы  Камышлы авылы мәдәният йорты бинасында һәм кибет бинасында мәгълүмати стенд.

- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru, адресы буенча

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис: А.М.Мөхәммәтшин